РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

ул. Г. Ахметова, д. 14а, село Агерзе,
Азнакаевского муниципального
района, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге Советы
**БАШЛЫГЫ**

Г. Әхмәтова урамы, 14а,
Әгерҗе авылы
Азнакай муниципаль районы,
423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» октябрь 2024 ел №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлегендәӘгерҗе торак пунктында гражданнарныңүзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пунктында теркәлгән Яшьләр урамы 1 йорттан 31 йортка кадәр сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2024 елның 18 октябрендә 9 сәгать 00 минутка беренче этабын билгеләргә. Үткәрү урыны: Яшьләр урамы, 23 йорт каршында.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пунктында теркәлгән Гафиатуллин урамы 1 йорттан алып 43 йортка кадәр, Г. Әхмәтов урамы 15 йорттан алып 24 йортка кадәр сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2024 елның 18 октябрендә 11 сәгать 00 минутка икенче этабын билгеләргә. Үткәрү урыны: Г. Гафиатуллин урамы, 24 йорт каршында.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пунктында теркәлгән Г. Әхмәтов урамы 1 йорттан алып 14 йортка кадәр, С. Сәйдәшев урамы 1 йорттан алып 24 йортка кадәр, Г. Тукай урамы 1 йорттан алып 26 йортка кадәр, С. Хәким урамы 1 йорттан 48 йортка кадәр сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2024 елның 18 октябрендә 14 сәгать 00 минутка өченче этабын билгеләргә. Үткәрү урыны: авыл мәдәният йорты.

4.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлегенең Башкарма комитетын;

гражданнар җыенынын үткәрү вакыты - 2024 елның 18 октябрендә 9.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр;
гражданнар җыенынын үткәрү вакыты - 2024 елның 18 октябрендә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
гражданнар җыенынын үткәрү вакыты - 2024 елның 18 октябрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
гражданнар җыенын үткәрү урыны - Әгерҗе авылы,Яшьләр урамы, 23 йорт каршында;
- гражданнар җыенын уздыру урыны - Әгерҗе авылы мәдәният йорты.
5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
-2024 елның 11 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авылы Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышуныӘгерҗе авылы Г. Әхмәтова урамы 14 а адресы буенча тәэмин итәргә.
- сайлау хокукына ия булган Әгерҗе торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Әгерҗе торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турындамәгълүматны башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга:

"Сез 2025 елда 1,2,3 төркем инвалидлар, өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тышТатарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:

- Әгерҗе авылы янындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Г.Гафиятуллин урамындагы шартнамә буенча эшләр өчен түләү, йөк төяү, күчереп йөртү, вак таш салу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны түбәндәге чаралар ярдәмендә халыкка игълан итәргә:
- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авыл җирлеге, Г.Әхмәтова ур., 14а йорт; Әгерҗе авылы Г.Әхмәтова урамы, Әгерҗе авылы С.Хәким урамы киселешендәге Г. Гафиатуллин урамындагы 10 һәм 23а йортлары арасында урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга;
- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.
- Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча»: http://aznakaevo.tatarstan.ru бастырырга.
Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге
Башлыгы Н.Н.Хәсәнов